**Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы**

КАРАР

«18» декабрь, 2023 ел № 31

Түбән Өскебаш авыл жирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 28 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл жирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 6 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2018 елның 31 октябрендәге 28 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 8 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 7 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 8 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 13 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 3 номерлы,2023 елның 30 октябрендәге 25 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Түбән Өскебаш авыл җирлеге башлыгына классны чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Түбән Өскебаш авыл җирлеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов